

Мордовиядә vткән «Жырлый торган агач» фестиваленә йомгак ясалды. Рос- сиянен 7 регионыннан килгән 13 катнашучы 5 кон дәвамында агачтан скульптура кисеп, Саранскига бvләк итеп калдырдылар.

«Жырлый торган агач» тобәкара фестиваль-конкурсы Саранскида бо- тен илдән vзенчәлекле осталарны жыйды. Биш конлек эшнен нәтижәсе - 12 скульптура. Алар узган ел коллекциясен «Мордовское подворье» музей-этнография комплексынын уникаль арт-мәйданчыгында тулыландырачак.
Саранскида «Жырлый торган агач» конкурсы «Шумбрат, Мордовия!» фестивале кысаларында vтә. Жюри әгъзалары быел катнашучыларнын бик кочле составы булуын һәм барлык эшләр дә диярлек лаеклылар икәнлеген билгеләп vттеләр. Шуна кvрә ин яхшы скульптураны сайлап алу авыр булган. Оч призлы урыннан тыш, кvп кенә катнашучыларны махсус призлар белән бvләкләгәннәр.



Жинvче булып Мордовиянен Кочкурово районы Подлесная Тавла авылыннан Петр Рябов танылды. Икенче урынны Мәскәv олкәсеннән Владимир Алманов алган.
Фестиваль нәтижәләрен игълан итәр алдыннан, оештыручылар тиз арада кисv конкурсын vткәрделәр. Оч катнашучы 45 минут эчендә оч скульптураны бензопила белән кистеләр. Биредә беренче урынны Владимир Алмановка, икенче урынны Петр Рябовка,

очечне урынны Пензадан Александр Туркичевка бирделәр.
Халык ижаты – ин югары зәвык, осталык, югары әдәплелек һәм чын патриотлык. Үз милләтенен хәзинәсен белгән, кадерен анлаган һәм яраткан кеше генә башка милләт сәнгатен анлый һәм хөрмәт итә. Шул сыйфатлар доньяда дуслык һәм тынычлык нигезе булып тора.

**Наилә НАСЫРОВА**